

# Татар әкиятләре

# Татарские сказки

УДК 000.0
ББК 000.0
М00

ТАТАР ӘКИЯТЛӘРЕ
татар һәм рус телләрендә
Олылар балаларга укыр өчен
әдәби-нәфис басма

Рәссам: Азат Миннекәев
Дизайн, биткә салучы: Дамир Җәләлетдинов
Татар текстларын әдәби эшкәртүче: Ркаил Зәйдулла
Тәрҗемәчеләр: Илдар Әбүзәрев, Алёна Кәримова, Айдар Хөсәенов
Гомуми редакция: Равил Бохараев
Редакторлар: Ләйсән Хафизова, Татьяна Мастюгина, Гәүһәр Хәсәнова
Корректорлар: Александра Конькова, Юлдуз Миңнуллина
Басмага әзерләүче: Ләйлә Җәләлетдинова
Проект координаторы: Юлия Володина

ТАТАРСКИЕ СКАЗКИ
на татарском и русском языках
Литературно-художественное издание
для чтения взрослыми детям

Иллюстрации: Азат Миннекаев
Дизайн, верстка: Дамир Залялетдинов
Литературная обработка татарских текстов: Ркаил Зайдулла
Переложение на русский язык:
Ильдар Абузяров, Алена Каримова, Айдар Хусаинов
Общая редакция: Равиль Бухараев
Редакторы: Лейсан Хафизова, Татьяна Мастюгина, Гаухар Хасанова
Корректоры: Александра Конькова, Юлдуз Миннуллина
Подготовка к печати: Лейля Залялетдинова
Координатор проекта: Юлия Володина

ISBN 978-5-903715-19-0

© ООО «Издательский дом Марджани»
© Азат Миннекаев, иллюстрации
© Дамир Залялетдинов, дизайн
© Ркаил Зайдулла, Ильдар Абузяров, Алена Каримова, Айдар Хусаинов, литературное переложение

## Эчтәлек / Содержание


| Эчтәлек | | Содержание |
|---|---|---|
| Алпамша һәм Сандугач | 3 | Алпамша и смелая Сандугач *(в переложении Айдара Хусаинова)* |
| Алтын каурый | 15 | Золотое перо *(в переложении Алены Каримовой)* |
| Алтын кош | 27 | Золотая птица *(в переложении Айдара Хусаинова)* |
| Ханбикә һәм Алтынчәч турында әкият | 43 | Сказка о жене падишаха и Алтынчеч *(в переложении Ильдара Абузярова)* |
| Ак бүре | 55 | Белый волк *(в переложении Алены Каримовой)* |
| Гелнәзек | 83 | Гульназек *(в переложении Ильдара Абузярова)* |
| Дутан батыр | 89 | Дутан батыр *(в переложении Айдара Хусаинова)* |
| Таңбатыр | 107 | Тан-батыр *(в переложении Айдара Хусаинова)* |



ООО «Издательский дом Марджани»
117997, Москва, Вавилова, 69
+7 (495) 234 0479 тел./факс
www.mardjani.ru

ООО «Типография «Новости»
105005, Москва, ул. Фридриха Энгельса, 46
+7 (499) 265 5418 тел./факс

# АЛПАМША ҺӘМ САНДУГАЧ
# АЛПАМША И СМЕЛАЯ САНДУГАЧ



Борын-борын заманда яшәгән, ди, Алпамша исемле егет. Әтисе дә, әнисе дә күптән үлгән, бу гел берүзе яши, ди. Көннәр буе ул кешеләр өчен көтү көткән. Аның бары бер сөенече булган, ул да булса думбра икән. Егет шулкадәр моңлы итеп уйный, ди, хәтта атлар уйланып кала, ди.

Яз мәлендә алып киткән Алпамша көтүне күл буена. Шунда очраган моңа бер кыр казы бәпкәсе. Ул аны тәрбиягә алып, үзе белән көтүдә йөртә, аның дусты бар бит хәзер!

Җәй үтә, көз җитә. Кыр казы үсеп җитә. Бер дә бер иртәдә Алпамша иртән дустын янында тапмый.

– Их, шайтан алгыры, асрадым, җәй буенча үзем белән йөрттем, икмәк ашаттым, нигә бу мине ташлап китте икән? – дип аптырый Алпамша.

Бераздан ул казны оныта: «Китте дә бетте инде бу», – ди.

Көтү көткән вакытта моңа бер карт очрый. Карт әйтә моңа:

– Алпамша, син үзең бик куәтле егет, Чабата тауда ярыш була шушы көннәрдә, шунда алдан чыккан кешегә хан Сандугач исемле кызын бирә икән, – ди.

– Аның, бабай, шартлары нинди соң? – дип сорый егет.

– Аның шарты шул: өч тегермән ташының икесен култык астына кыстырып, берсен кулга киеп, тауга менгән кешегә хан үзенең кызын бирә.

Алпамша уйлап та тормый, икенче көнне көтүен ташлап, ярыш була торган урынга китә.

Барып җитә мәйданга. Мәйданда бихисап халык җыелган. Алпамша ярышка чыгучылар янына килеп баса. Моның кием начар, кыяфәт тә әлләкем түгел, көләләр генә моңардан. Катнашмый бу сүзләргә дә, сөйләшми беркем белән. Ничек кенә сынатмаска соң болар каршында?

Батырлар бер-бер артлы ташларны күтәреп алалар да, тауга йөгерәләр, аннан соң, икенче ташны алырга дип, аска чабалар икән. Аста өченче таш көтеп тора бит әле.

Бервакыт чират безнең егеткә килеп җитә. Алпамша ташларны бер-берсенә бәреп яра да, ике ташны кулына киеп, ярылган ике ташны култык астына кыстырып, тауга менеп китә. Халык ах иткән: «Юк кына кеше, менеп китте бит», – дип шаккатып карап калган болар.

Менеп җитә бу тау башына. Хан тау башында утыра икән. Ул Алпамшаны затлы киендереп, яхшы атларга утыртып алып кайтып китә. Кайткач туй ясыйлар. Хан ярты дәүләтен бирә Алпамшага.

– Яртысына мин җавап бирәм, яртысын син кара, – ди.

Жил-был на свете юноша по имени Алпамша. Давно уж умерли его отец, мать и вся родня, а друзей близких у него не было. Один-одинешенек день-деньской пас он чужой скот в широкой степи.

Была у юноши отрада – домра, на которой он играл, а еще была у него песня, которую пел он так задушевно, что даже кони заслушивались.

Однажды ранней весной Алпамша погнал стадо на водопой. Там, на берегу озера, попался ему подраненный дикий гусенок.

Выходил он гусенка, выкормил, играл с ним, разговаривал, так что гусенок от него уже ни на шаг не отходил. И Алпамша был рад, что товарищ у него появился.

Прошло лето, настала осень, стаи птиц потянулись на юг. Как-то проснулся ранним утром Алпамша, кличет своего друга, а дозваться не может – улетел, видать, гусь, пристал к перелетной стае. Огорчился Алпамша, да делать нечего, надо жить дальше.

Однажды встретился ему в степи какой-то старик. Рассказал старик, что падишах страны устраивает в таком-то месте, на такой-то горе состязание батыров. Кто победит – тому достанется его дочь, храбрая и прекрасная Сандугач, а с нею вместе – половина царства.

– А что за состязание, каковы его условия? – спрашивает Алпамша.

– А условия такие, – отвечает старик. – Кто три мельничных жернова на гору быстрее всех принесет да рядом с падишахом положит – тот и победил!

Попрощался Алпамша со стариком и лег себе спать. Утром проснулся и недолго думая отправился на ту гору, где падишах проводил состязание батыров.

Подошел Алпамша к горе, смотрит – собралось тут людей видимо-невидимо: весь народ от мала до велика. Поодаль стоят батыры – все нарядные, в своих лучших одеждах.

Подошел юноша и смело встал рядом с ними. Одежда на нем была самая простая и старая, да и что сказать: пастух, он и есть пастух. Стали над ним смеяться – мол, куда лезешь, лучше бы стадо свое пас. Молчит Алпамша, в разговоры не вступает.

Вдруг зашумела толпа – состязания начались. Один за другим батыры хватают по жернову и на гору бегут. Один жернов притащат, спускаются за вторым, а там еще и третий своей очереди дожидается. На горе стоит падишах со своими приближенными



Шуннан берничә генә ай элек Кылтап дигән бер патша Сандугачка яучы җибәргән икән. Ханга:

– Кызыңны бирсәң бирәсең, бирмәсәң, сугышып алам, – дип әйттергән бу.

Хәзер кыз кияүдә инде, Кылтап патша теләсә нишләсен! Теләгәнен эшли – Алпамша иленә каршы сугыш ача. Кылтап патшаның сугыш башлавы турындагы хәбәрне ишеткәннән соң, Алпамша бабасы белән киңәшә.

Алпамша, хатыны Сандугачны алып, яуга үзе генә китәргә ниятли.

и смотрит, кто быстрее да ловчее камни таскает.

Дошла очередь и до Алпамши. Схватил он два жернова, ударил друг о друга, один из них и раскололся. Сунул юноша половинки под мышку, два других камня руками подцепил и вихрем взлетел на гору! Народ ахнул: «Как это так? Простой пастух знаменитых батыров обошел!»

Обрадовался падишах, что в его стране такой батыр объявился, повез юношу во дворец. Справили свадьбу, и стал юноша зятем падишаха.

Бабасы әйтә:

– Минем атлар арасыннан үзегез теләгән атны сайлап алыгыз, – ди.

Алпамша, кала читендәге аранга барып, ат сайларга керешә. Һәр атның койрыгын тартып карый. Койрыгыннан тартып җибәрә – атның тиресе суырылып чыга. Аранда яраклы ат табылмый. Икенче аранга кереп, бер атның койрыгын тартып җибәрсә, ат селкенеп кенә куя. Алпамша: «Менә бу ат миңа ярарлык ат икән», – ди.

Өченче аранда Алпамша Сандугач өчен ат сайлый. Бу һаман шулай эшли, атның койрыгыннан тартып җибәрә – тиреләре суырылып кына чыга. Бераз йөргәч, ябага гына бер атка тап була: койрыгын тартып карый – теге ябага кушаяклап моңа тибеп тә җибәрә.

– Бу Сандугачка яраклы ат, – дип, Алпамша шушы ябага атны сайлап ала.

Китеп баралар Алпамша белән Сандугач яу кырына. Баралар, баралар болар, бара торгач, Кылтап патша туктаган яу кырына барып җитәләр. Алпамша Сандугачка әйтә:

– Мин, ничек тә алдап-йолдап, Кылтап патшаның Акбүз атына менәргә тиешмен, шул Акбүз атта мин аны җиңәрмен!

Ул Сандугачны яшереп, Кылтап патша урдасына китә. Гаҗәп гүзәл бакча эчендәге чатырда Кылтап патша җәйрәп йоклап ята икән. Шул вакытта Алпамша чатыр янына бара да бер-ике җыру әйтә:

*Кылтап бабай,*
*Кылтап бабай,*
*Акбүз атың бирсәң, агай,*
*Сандугачың үзеңә булсын!*

Шушы җыруны ике мәртәбә әйткәннән соң, Кылтап патша: «Сандугач хакына Акбүз атны да бирәм», – дип уйлап, йокы аралаш:

– Акбүз атым Тубылгы тау астында, таң алдыннан чишмәгә су эчәргә төшәр, янында алты ат булыр, – дип мыгырдый.

Алпамша белән Сандугач кояш чыккан вакытта чишмә янына барып җитәләр. Бер агач төбендә утырып, Акбүз атны сагалыйлар. Атлар чишмәгә төшә, әмма аларның җидесе дә акбүз икән! Алпамша колак сала: берсенең тояклары атлаганда, «кылтап-кылтап» дип тавыш чыгара. Шул вакытта Алпамша әлеге Акбүз атны, тезгененнән тотып алып, имән агачына бәйләп куя. Атлар алтын иярләр белән иярләнгән, иярләргә алтын кылычлар бәйләп куелган.

Акбүз атны Сандугач үзенә ияләндергәннән соң,

– За эту половину царства я отвечаю, а вот за эту тебе придется ответ держать, – сказал ему падишах. На том и сошлись.

Наутро сели они совет держать. Оказывается, падишах по имени Кылтап – правитель соседнего царства – объявил им войну. А все потому, что недавно сам посылал он сватов к прекрасной Сандугач, но она отказалась за него замуж идти. Разозлился Кылтап: мол, добром не хочешь, силой возьму!

Ничего не поделаешь, теперь придется воевать с Кылтапом! Решил Алпамша на войну идти не один, а с любимой женой. Попросили они у падишаха коней.

– Ступайте в степь, – отвечает им падишах. – Сами выберите в моих табунах.

Вышли Алпамша и Сандугач в степь, стали коней себе выбирать. Какого за хвост ни дернет юноша, конь замертво падает. Наконец набрели на неказистую облезлую лошаденку. Дернул ее за хвост Алпамша, а она стоит себе, даже не шелохнется.

Обрадовался юноша: «Вот такого коня я искал!»

Обошли они весь табун, нашли еще одну такую же крепкую лошадь для Сандугач.

Вернулись во дворец. Пора им в поход отправляться. Говорит падишах:

– Раз такое дело, проводим вас с почестями да с музыкой.

– Не надо нам ни почестей, ни музыки, – говорит Алпамша. – Мы отправимся тайно, чтобы никто ничего не знал, не ведал.

Распрощались они с родными и близкими и отправились во главе войска в поход на падишаха Кылтапа.

День ехали, ночь ехали, наконец достигли владений своего врага. Тут и говорит Алпамша:

– Есть у падишаха Кылтапа волшебный конь Акбузат. Давно о нем слава идет по всему свету. Без него не одолеть нам врага.

Но как того коня увести у падишаха?.. Пробрался темной ночью Алпамша во владения Кылтапа, все табуны обшарил, да только Акбузата так и не сыскал. Не знает, каков он из себя, по какой примете его можно узнать.

Недолго думая, подкрался Алпамша к тому месту, где спал сам падишах. И запел – тихо-тихо, чтобы не разбудить стражу:

*Кылтап-бабай, Кылтап-бабай,*
*Где Акбузат, скажи, давай!*
*Коль Акбузат умчится вскачь,*
*Твоею будет Сандугач!*



үзләренең атларын ташлап, Акбүз атка атланып китәләр. Кылтап гаскәре аларны бастырып куа башлый. Тик Алпамша белән Сандугач бит бу турыда белми. Шактый озак юл киткәч, болар ял итәргә туктый.

– Унике көн, унике төн йокламадым. Мин хәзер йоклыйм, – ди Алпамша. – Мин йокыга киткәч, яу килсә, син мине уятырсың, – ди дә Сандугачка ун гөрәнкәле чүкеч белән бер без бирә. – Уята алмасаң, шушы безне алып, минем маңгайга куеп, шушы чүкеч белән сугарсың, мин шул вакытта гына уянырмын.

Бер заман Кылтап гаскәрләре килеп җитә. Сандугач

Имя красавицы разбередило душу падишаха, забормотал он во сне да и рассказал приметы Акбузата и как его найти, – конечно, ведь такая красавица стоит коня!

На рассвете добрался Алпамша до того места, о котором рассказал во сне падишах Кылтап, – до заветного озера. Смотрит – вышли из леса на водопой шесть жеребцов, один другого краше.

С первого взгляда опознал Алпамша Акбузата, неслышной тенью подкрался он к волшебному коню и схватил его за золотую уздечку. Встал Акбузат как вкопанный. Признал нового хозяина.



аптырашта кала, Алпамшаны уятыр иде, үтермен дип курка.

Шунда ул дошман явына үзе генә каршы барырга уйлый. Акбүз атка атлана да Кылтапның гаскәренә каршы китә. Берникадәр кешене кылыч белән чаба. Җегәре беткәннән соң, үзен дә яралыйлар. Шулай да бу тегеләрне куып җибәрә. Тегеләрне куып җибәргәч, Алпамша янына барып ял итә.

Кылтапның качкан яугирләре барып әйтәләр: «Алар гаскәрендә баһадир бар», – диләр. Болар хәзер инде Кылтапның үзен алып киләләр.

Яңадан Кылтап патшага каршы Сандугач үзе генә китә. Алпамшаны уятыр иде, үтермен дип курка.

Бик каты сугышканнан соң, Сандугач, авыр яраланып, атасының йортына кайтып китә. Кылтапның яугирләре йоклап яткан Алпамшаны тотып алалар. Акбүз ат та шунда була. Кылтапның елкычылары Акбүз атны алып кайтып китә. Рәшәткәле чуен баз койдырып, Алпамшаны шул зинданга ябалар.

Алпамша өч атна йоклагач кына уяна. Аптырый инде – зинданда ята бит. Өстәвенә ашыйсы да, эчәсе дә килә. Шунда гына аңлап ала эшнең нидә икәнен: дошманнар гаскәрне кисеп бетергәннәр, ә үзен тоткын итеп алганнар икән бит. И кайгырган Алпамша, нишләргә инде хәзер?

Инде көз җитә. Кыр казлары тезелеп оча. Алпамша моңланып җырлап җибәрә:

*Кыйгак казлар,*
*Кыйгак казлар,*
*Бармыйсызмы*
*Безнең якка?*
*Әгәр барсагыз безнең якка,*
*Хат язаем ак канатка.*

Казлар арасында очып баручы ятим каз, моны ишетеп, Алпамша янына килеп төшә. Үзе тәрбияләп үстергән теге кыр казы икән бу! Алпамша шунда Сандугачка хат яза: «Миңа бер йөк пешкән икмәк, бер мичкә су җибәр», – дип үтенә, думбрасын да сорый. Тоткынга моңланырга кирәк бит! Хат ахырында: «Миннән йөз сум акча алган дустым бар иде, аңа әйт, ул килер; ул килмәсә, шөшле биргән бер дустым бар, аңар әйт, ул килер», – дип өсти.

Кыр казы очып китә дә хан сараеның түбәсенә куна. Хат язылган каурыен йолкып ата да, үзе тиз генә очып китә. Моны Сандугачның сеңелесе күреп кала. Шул вакытта ук апасына кереп әйтә. Апасы белән бергә әлеге канатны алып укыйлар. Шуннан болар Алпамшаның исән икәнлеген беләләр.

Сандугач Алпамшаның йөз сум биргән дустына бара:

Вернулся Алпамша к своему войску, говорит жене:

– Двенадцать дней и ночей я не спал, глаз не сомкнул. Лягу я спать, а ты сон мой стереги. Как появится войско падишаха Кылтапа, разбуди меня! Только буди как следует – ведь сплю я сном богатырским!

Уснул Алпамша, а тут и вражье войско появилось. Стала Сандугач будить мужа, а он не просыпается. И так пробует, и эдак – не просыпается батыр. А войско вражеское – вот оно, рядом, ждать не будет.

Надела тогда Сандугач доспехи мужа, вскочила на Акбузата и поскакала на врага. Порубила многих, рассеяла вражеское войско по полю, прогнала.

Разозлился падишах Кылтап, узнав о поражении. Собрал он войско еще большее, чем прежде, сам встал во главе и двинулся в поход.

Наутро видит Сандугач – снова идет вражеское войско. Снова стала она будить мужа, а он не просыпается. И так пробовала, и этак – спит Алпамша.

Вскочила тогда Сандугач на Акбузата и снова пошла в бой. Да только на этот раз удача отвернулась от нее – ранили девушку. Верный Акбузат вынес Сандугач с поля битвы и унес к родному дому. А падишах Кылтап захватил спящего Алпамшу в плен.

Посадили его в подземную тюрьму, закрыли тюрьму крепкой решеткой.

Три недели спал батыр, наконец проснулся и открыл глаза. Что такое? Понять не может. Наконец догадался он, что враги разгромили его войско, а самого взяли в плен.

Пригорюнился Алпамша, не знает, что теперь делать. Вдруг услышал он крики в небе. Это летели перелетные гуси. Подумал Алпамша: «Не летит ли в этой стае мой друг?» И запел он грустную протяжную песню:

*Куда, куда летите, гуси?*
*Не до родных моих краев?*
*Ах, сам туда не доберусь я,*
*Письмо бы взяли вы мое!*

Смотрит – отделился от стаи гусь, летит на знакомый голос. Обрадовался Алпамша и написал на крыле гуся письмо своей жене: так, мол, и так, пришли мне воз хлеба, бочку воды и любимую домру. А в конце сделал приписку: «Есть у меня знакомый – я ему когда-то денег одолжил, пусть придет. Если он откажется, обратись к другому моему знакомому – я в свое время давал ему кочедык – лапти плести».

– Алпамша бер йөк икмәк, бер мичкә су сораган, барамсың илтергә? – ди.

– Вакытым юк, – дип җавап бирә теге.

Китә Сандугач Алпамшаның шөшле биргән дустына. Шөшле биргән дусты берсүзсез риза була – бер йөк икмәк, бер мичкә су, думбрасын калдырмыйча, чыгып китә юлга.

Барып җитә бу дала түренә. Чуен зиндан эчендә яткан Алпамша ат аягы тавышын ишетә. Алпамшаның дусты аны күрми, чуен зиндан бит җир астында. Иптәшенең тавышын ишеткәч, Алпамша җырлый:

*Дөп иткән,*
*Дөп-дөп иткән*
*Аю микән, бүре микән?*
*Әллә минем*
*Йөз сум биргән*
*Дустым микән,*
*Дустым микән?*

Җавап бирүче юк. Шуннан соң Алпамша тагын җырлый:

*Дөп иткән,*
*Дөп-дөп иткән*
*Аю микән, бүре микән?*
*Әллә минем*
*Шөшле биргән*
*Дустым микән,*
*Дустым микән?*

Шул вакытта теге шөшле биргән дусты:

– Әй, дустым, син кайда? – дип тавыш бирә.

Иптәше икмәкне, суны, думбраны тапшыра да инде кайтмак була. Бу киткән вакытта Алпамша берничә сүз әйтә:

– Минем хатынга әйт, мине ике ел көтәр, ике елдан соң тагын ике ел көтәр, ул ике елдан соң тагын бер ел көтәр. Әгәр шуннан соң да кайтмасам, үзе теләсә нишләсен...

Кала Алпамша зинданда. Тамак тук, думбра бар. Уйный, тик читлектән генә чыга алмый.

Озак уйный батыр, моңланып җырлап та ала. Уйнаудан туктагач, кемнеңдер сулкылдап елавын ишетә. Кылтапның кызы далага күңел ачарга чыккан да Алпамшаның моңлы тавышын ишеткән икән.

Эзләп таба кыз зинданны. Читлек аша сорый:

– Алпамша дигән егет син буласыңмыни? – ди.

Бу вакытта инде Алпамшаның даны еракка таралган була. Халык аның әсирлеккә төшүе турында бәетләр чыгара.

– Әйе, мин... Мәнә зинданга яптылар, бөтенләй харап итәргә телиләр ахрысы, – дип җавап бирә батыр.

Ошата патша кызы тоткын егетне. Моңлы булуы

Улетел гусь, добрался до дворца, где жила Сандугач, бросил вниз перо, на котором письмо было написано, и улетел. Увидела перо младшая сестрица Сандугач, прочитала и отдала своей старшей сестре. Так они и узнали, что Алпамша жив-здоров, находится в плену.

Пошла Сандугач к тому человеку, который когда-то занял денег у Алпамши, попросила о помощи.

– Не было такого, – отвечает человек. – Никаких денег не брал, помочь ничем не могу.

Пошла тогда Сандугач к другому человеку, который взял у Алпамши кочедык. Выслушал юноша горестный рассказ, встал и, не мешкая, отправился в дорогу.

Вот едет он по широкой степи, стучат колеса его повозки. Услышал тот стук в своей подземной тюрьме Алпамша и запел:

*Кто тут мимо прошагал,*
*Волк или медведь?*
*Может, тот, кто деньги брал?*
*Нет, не разглядеть.*

Стихли звуки, пропали. Умолк Алпамша. Вдруг слышит, снова кто-то по степи едет. Запел он тогда другую песню:

*Ты джигит или старик,*
*Воин или князь?*
*Может, взявший кочедык*
*Отыскал меня?*

Услышал друг эту песню и подбежал к решетке. Это он кружил по степи, никак не мог отыскать подземную тюрьму. Передал он Алпамше воз хлеба, бочку воды и любимую домру. Собрался в обратную дорогу.

– Передай жене, – сказал Алпамша, – чтобы ждала меня два года, потом еще два, да потом еще один год. Если и тогда не вернусь – пусть поступает как знает!

Остался Алпамша один. Грустно ему стало, одиноко. Заиграл он на домре печальную мелодию. Долго играл батыр, а когда перестал, услышал тихий плач. Это плакали дочь падишаха Кылтапа и ее старая нянька. Вышли они погулять в степь да и забрели в эту сторону. Услышали мелодию, и слезы сами собой потекли по их щекам.

– Так ты и есть Алпамша? – спросила дочь падишаха. Она была наслышана о храбреце, которого захватило войско ее отца.

– Да, это я. Заточили меня в подземную тюрьму, хотят погубить, – ответил батыр.

Приглянулся девушке храбрый юноша, стала она каждый день к нему приходить, разговоры вести.



өстенә чибәр дә икән Алпамша. Теләсә нинди кызның күзе төшәрлек. Кыз аның янына көн саен килеп йөри башлый. Аның бу эше турында шымчылар атасына җиткерәләр. Кылтап патша ачуыннан нишләргә белми инде, табигый.

Уйлый-уйлый да, Алпамшаны кызының кулы белән һәлак итәргә ниятли ул.

Кызын чакыра да, аңа агу биреп, Алпамшаның башына сибәргә боера. Әтисенең холкын яхшы белгән кыз, агуны алып, күндәм генә зинданга юнәлә. Тик Алпамшаны күргәч, аның тавышын ишеткәч, патшаның боерыгын үтәүдән баш тарта. Алпамша да кызны хуплый:

– Агуны далага түк тә әтиеңә мине агулавың турында кайтып әйт, – ди. – Әгәр моннан коткарырга

Узнал о том падишах Кылтап – страшно разгневался. Вызвал к себе дочь и приказал ей в следующий раз вылить яду на голову батыра. Не посмела дочь перечить отцу, согласилась. Но пришла она к яме, стала разговаривать с батыром и позабыла о своем дочернем долге – рассказала Алпамше, что отец приказал отравить его.

– Вылей яд на землю, а отцу скажи, что отравила меня, – ответил ей батыр. – А сама добудь для меня драгоценный алмаз, что хранится у твоего отца. Он поможет мне распилить решетку.

– Как же я его возьму? – отвечала дочь падишаха. – Ведь его сторожат две злые собаки.

– А ты разорви на себе платье и скажи, что собаки на тебя напали, – говорит ей Алпамша. – Пока твой отец

уйлыйсың икән, иң элек син миңа күлмәк-ыштан алып кил, – дип шарт та куя әле.

– Соң мин сине ничек итеп коткарыйм, гаскәр алып килимме?

– Юк, – ди Алпамша. Гаскәр кирәкми, минем турыда тавышланырга ярамый. Син мине коткарасың килсә, атаңның сандыгында чуен кисә торган бер алмаз бар, шуны алып килсәң, мине коткара алырсың... Ләкин атаң янына керергә бик зур хәйлә кирәк. Атаңның хөҗрәсенә кергәндә, ике эт булыр, шуларның берсенең аягына бас, аягына басу белән, ул этләр сиңа ташланыр, киемеңне ертып ташлар. Син, елап, атаңа кереп әйт: «Шул этләреңне үтерергә булмыймы, сиңа эт якынмы, кызың якынмы?» – диген. Атаң эт янына чыгып киткәч, син атаңның алмазын алырсың да минем янга килерсең.

Кыз атасы янына кайтып китә. Кайтып, атын тугармыйча гына, атасы янына керә. Атасының ишек алдында яткан этенең аягына баса. Ике эт бик нык таларга керешәләр. Кыз этләрдән ычкына да, атасы янына үтеп, аның аягына егылып елый. Кылтап патша этләрне кыйнарга чыгып китә. Атасы чыгып китү белән, кыз алмазны ала да, икенче бүлмәгә чыгып, чалбарлар, күлмәкләр җыеп, Алпамша янына китә.

– Мин сине моннан ничек кенә коткарыйм икән? – дип өзгәләнә кыз.

– Син, – ди Алпамша, – чуен зиндан өстенә менеп, рәшәткәне алмаз белән сыз, аннан соң мин үзем ачармын.

Кыз берничә мәртәбә алмаз белән чуен өстенә сызганнан соң, Алпамша аягы белән тибеп этеп җибәрә, чуен рәшәткә өчкә-дүрткә ватыла. Алпамша якты дөньяга чыга.

Зинданнан чыккач, кыз алып килгән киемнәрне киеп куя Алпамша.

– Гафу ит мине, чибәр кыз! Өйдә мине хатыным көтеп тора.

Сызгырып җибәрә Алпамша, каршына Акбүз ат килеп баса.

Акбүз ат белән Алпамша Сандугач янына кайта. Үзе уйлый:

– Мине сарайда көтәләрме икән?

Шәһәр читенә кайтып җитә дә, Акбүз атны үләнгә җибәрә. Көтүче вакытта торган алачыкка кереп, затлы киемен сала, янә көтүче киеменә төренә.

Шәһәргә кереп, бер карчыкның өенә төшә. Алпамша карчыктан шәһәр хәлләрен сораштыра. Карчык аңа шәһәрдә ниләр булганын сөйләп бирә:

будет их наказывать, ты сможешь незаметно взять алмаз.

Так и сделала девушка – Алпамша словно в воду глядел. Ужасно разгневался на своих верных псов падишах Кылтап, стал их плеткой бить, а его дочь за это время отыскала алмаз.

Прибежала она к яме, где томился батыр, стала пилить решетку. Долго пилила, устала.

– Давай теперь я попробую, – сказал ей батыр. Схватился Алпамша за решетку, раскачал ее и сломал. Вышел он из подземной тюрьмы, умылся у ближайшего источника, переоделся в одежду, что дала ему дочь падишаха.

– Пойдем со мной, – сказала ему девушка. – Я спрячу тебя у себя во дворце, там никто тебя не найдет!

– Прости меня, славная девушка! – ответил ей батыр. – Ждет меня дома верная жена!

Свистнул он условным свистом, и предстал перед ним волшебный конь Акбузат, – разорвал путы, которыми был стреножен, и примчался на зов хозяина. Попрощался Алпамша с девушкой и ускакал прочь. Не успел и глазом моргнуть, как очутился на окраине родного города.

– Интересно, ждут меня во дворце или нет? – подумал Алпамша. Чтобы не искушать судьбу, переоделся он в нищенские лохмотья, а Акбузата отпустил. Постучался в маленькую избушку, попросился переночевать. Старушка-хозяйка встретила его приветливо, напоила, накормила, расспросила, кто таков, откуда и куда путь держит. Рассказала и о том, что в городе творится.

– Дочь падишаха, храбрая Сандугач, завтра выходит замуж, – сказала она. – Будет по этому поводу устроен большой праздник, так что всякий сможет прийти во дворец да поесть угощений с царского стола.

Наутро отправился Алпамша во дворец. Ходит из зала в зал со своей нищенской сумой, осматривается. Смотрит – сорок джигитов не могут его лук разогнуть да стрелу в небо пустить.

Увидела его в образе нищего младшая сестрица Сандугач и говорит старшей:

– Вон тот нищий чем-то Алпамшу напоминает.

– Я уж почти забыла о нем, – отвечает ей Сандугач. – Ведь ждала я его два года, а потом еще два, а потом еще один год и один день. Он сам сказал: «Поступай потом, как знаешь!»

– А вдруг это он пришел посмотреть, радуешься ли ты новому жениху? – говорит сестрица.